**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3453**
**27.04.2023**

Башкарма комитетның 2020 елның 7 октябрендәге 5118 номерлы карары белән расланган җирләрне консервацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 7 октябрендәге 5118 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 12 мартындагы 1710 номерлы карары редакциясендә) белән расланган җирләрне консервацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 3.3.1 пунктына, икенче абзацны төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов